**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче
Бәйрәкә-Тамак торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**17.11.2023ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге составына керүче Бәйрәкә-Тамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

-Бәйрәкәтамак торак пунктында зират территориясендәге койманы ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкәтамак торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы өчен МАФ сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) ” соравы буенча.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 207 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 110 кеше катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында 110 катнашучы «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар чыгарды:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге Бәйрәкә-тамак торак пунктында халык җыены узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. ."Сез 2024 елда үзара салым кертүгә Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге территориясендә Бәйрәкә-Тамак авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?:

-Бәйрәкәтамак торак пунктында зират территориясендәге койманы ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкәтамак торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы өчен МАФ сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү) ” буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Бәйрәкә-Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Җыенда рәислек итүче
Бәйрәкә-Тамак авыл җирлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Локманов